Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XXXII-4**

Балык Бистәсе штп. 24 июль 2018 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 4 апрелендәге XXVI-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актларны законнарга тәңгәлләштерү максатында Татарстан Республикасының 2017 елның 14 декабрендәге "Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турындагы Кодексына үзгәрешләр кертү турында"гы 90-ЗРТ номерлы, 2017 елның 23 декабрендәге "Россия Федерациясенең аерым закон актларына, адреслылык һәм мохтаҗлык критерийларын куллану принцибын үтәү йөкләмәсеннән чыгып, социаль яклау чараларын тәкъдим итүне исәпкә алу һәм камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында" Федераль закон кабул ителү белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында"гы 98-ЗРТ номерлы, 2018 елның 22 мартындагы "Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында"гы 15-ЗРТ номерлы законнарына таянып,Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль районы Уставына туры китереп, Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районСоветының 2013 елның 4 апрелендәге XXVI-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 22 июлендәге XXVII-6 номерлы, 2014 елның 14 августындагы XXXIX-3 номерлы, 2014 елның 13 декабрендәге XLII-8 номерлы, 2015 елның 14 ноябрендәге V-3 номерлы, 2016 елның 23 апрелендәге X-8 номерлы, 2916 елның 16 ноябрендәге XIII-9 номерлы, 2017 елның 29 маендагы XIX-9 номерлы, 2017 елның 23 октябрендәге XXII-6 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2.6.7 пунктында "2018 елның 1 гыйнвары" сүзләрен "2020 елның 1 октябре" сүзләренә алмаштырырга;

2) 16.7 маддәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"16.7.Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия исәпләп чыгарганда һәм билгеләгәндә айлык акчалата түләү составына вазыйфаи оклад һәм класслы чин өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә кертелә";

3)түбәндәге эчтәлектәге $16^1$ маддәсе белән тулыландырырга:

“$16^1$.Тиешле еллар эшләгән өчен пенсияне билгеләү һәм түләүне мәгълүмати тәэмин итү

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 28.1 маддәсенә туры китереп, Татарстан Республикасы Кодексы нигезендә муниципаль хезмәттә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү һәм түләү турындагы мәгълүмат Социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла. Күрсәтелгән мәгълүматны Социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру (алу) 1999елның 17 июлендәге “Дәүләт социаль ярдәме турында”гы178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә тормышка ашырыла.”.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә һәм 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала.

3.Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе
урынбасары И.Г.Ибраһимов